РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел.(84342) 5-13-38, тел/факс 5-13-38, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 19 марты** **Чистай шәһәре** **№ 38**

Чистай шәһәр Башкарма комитетының
2018 елның 27 июнендәге 139 номерлы
карары белән расланган Чистай шәһәре
территориясендә ваклап сату сәүдә челтәренең
стационар булмаган сәүдә объектларын һәм
вакытлыча җәмәгать туклануы объектларын
урнаштыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында.

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының бердәм коллегиясенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы бурычлары буенча беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәр Башкарма комитетының 2018 елның 27 июнендәге 139 номерлы карары белән расланган Ваклап сату челтәренең һәм вакытлыча җәмәгать туклануы объектларының стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.14 пунктының икенче абзацында түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«,Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмаска тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садиковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов